ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**21 гыйнвар 2019 ел** **№ 9**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында Арча-Сеҗе» - Иске Масра» автомобиль юлы объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектлары буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы уставы, Арча муниципаль районы Советының 2008 елның 27 декабрендәге 220 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районында гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында Арча-Сеҗе» - Иске Масра» автомобиль юлы объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектлары буенча гавами тыңлаулар уздырырга (1 нче кушымта).
2. Билгеләргә:
2.1. гавами тыңлаулар уздыру вакыты - 25.02.2019 ел, 17.00 сәгатьтә;
2.2. Үткәрү урыны - Арча муниципаль районы башкарма комитеты бинасы, адресы буенча: Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт;
2.3. Фикер алышкан мәсьәлә буенча тәкъдимнәр кертергә мөмкин адрес: ТР, Арча районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт (эш көннәрендә - 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр);
2.4. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар бирү срогы - 22.02.2019ел(тел. 3-12-44).
3. Арча муниципаль районы башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тәртип һәм билгеләнгән вакытта күрсәтелгән сорау буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.
4. Әлеге карарны 2019 елның 23 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Арча муниципаль районы башлыгы И.Г. Нуриев